ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
*БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*
***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ***

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
*БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН*
***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ***

---

**КАРАР**
**РЕШЕНИЕ**

27.01.2025 №1-58

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Буа шәһәр Советының 2018 елның 05 июлендәге 1-34 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставын (Буа шәһәр Советының 17.09.2019 ел, № 1-44, 30.07.2020 ел, № 1-59, 25.06.2021 ел, № 1-10, 03.10.2022 ел, №1-22 , 18.12.2023 №2-41 карарлары редакциясендә) гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, ТР Буа муниципаль районының Буа шәһәр Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы муниципаль районы Буа шәһәр Советы карары проектын (1 нче кушымта) беренче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

- эшче төркем җитәкчесе:

Зайцева Светлана Анатольевна-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре башлыгы урынбасары;

- эш төркеме әгъзалары:

Сафин Алмаз Марс улы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе;

Егоров Иван Павлович-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе;

Вәлиева Резеда Нәгыйм кызы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының җирлекләр җирле үзидарәсе органнары белән эшләү бүлеге башлыгы;

Халитова Илвина Илдар кызы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге баш белгече.

**3.** Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәр Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422430, ТР, Буа районы, Космовский ур., 91Б й., язма рәвештә, карар проекты рәсми басылып чыккан көннән алып 30 көн эчендә, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларда катнашып чыгыш ясау хокукы өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: 422430, ТР, Буа районы, Космовский ур., 91Б й, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты Буа шәһәр Советының 2021 елның 11 февралендәге 6-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәдә каралган тәртиптә әлеге проект буенча гавами тыңлауларны 26.02.2025 елда 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Башкарма комитетының утырышлар залында 422430, ТР, Буа районы, Космовский ур., 91Б йорт адресы буенча үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (https://buinsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**5.** Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проектына тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә.

**6.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре башлыгы
Совет Рәисе Р.Р. Камартдинов

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Буа шәһәр Советының 2018 елның 05 июлендәге  1-34 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставын  (Буа шәһәр Советының 17.09.2019 ел, № 1-44, 30.07.2020 ел, № 1-59, 25.06.2021 ел, № 1-10, 03.10.2022 ел, №1-22 , 18.12.2023 №2-41 карарлары редакциясендә) гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, ТР Буа муниципаль районының Буа шәһәр Советы

КАРАР  КАБУЛ  ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәр Советы карары белән кабул ителгән Буа шәһәре муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 13 статьяның 5 һәм 8 өлешләрендә «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен тиешле килештә «муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 30 статьяның 61 өлешендәге 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында «җирлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.3. 33 статьяның 1 өлешендә:

17 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

35 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

36 пунктчада «федераль законнарда» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон белән» «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы законы белән»сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 40 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11.1 пункт өстәргә:;

«11.1 аның чит ил агенты статусын алуы;»;

1.5. 43 статьяның 7 өлешендәге 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында «җирлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.6. 49 статьяның 1 пунктындагы 6 пунктчасының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын

һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

1.7. VII бүлекне һәм 58 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

1.8. 63 статьяның 3 өлешендә «һәм җирлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 77 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 77 статья . «Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе»

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек була торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

1.10. 79 статьяда:

«2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;».

түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Җирлекнең әлеге статьяның 1 өлеше таләпләренә туры килми торган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килгән очракларда күрсәтелгән мөлкәт яңадан профильләштерелергә (мөлкәтнең максатчан билгеләнеше үзгәрергә) йә читләштерелергә тиеш. Мондый мөлкәтне читләштерү тәртибе һәм сроклары федераль закон белән билгеләнә.».